| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ |
|---|---|

ПРИКАЗ БОЕРЫК

27 декабрь 2016 Казан шәһәре № 105

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы указлары нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау турында» 2014 елның 14 августындагы 78 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Хокук идарәсенең юридик бүлегенә шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкчесе В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2016 елның «27» декабрендәге 105 номерлы боерыгы белән расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕНДӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕНЕҢ ВАКАНТЛЫ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮГӘ (КАДРЛАР РЕЗЕРВЫНА КЕРТҮГӘ) КОНКУРС УЗДЫРУ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс (алга таба – конкурс) уздыру тәртибен, шартларын һәм методикасын билгели.

Конкурс Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә (алга таба – граждан хезмәте) тигез дәрәҗәдә үтеп керүенең конституциячел хокукын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукын тәэмин итә.

1.2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә (алга таба – Инспекция) конкурс «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 22 статьясы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы указы нигезендә уздырыла.

Конкурс Инспекциядә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасын) биләүгә дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның әлеге вазыйфага карата билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Инспекциядә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе җитәкчесе (алга таба – җитәкче) карары белән Инспекциянең дәүләт граждан

хезмәте буенча вакантлы вазыйфа барлыкка килгән структур бүлекчәсе җитәкчесенең Инспекциянең дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте бүлеге белән килештерелгән язмача дәлилле мөрәҗәгате нигезендә игълан ителә (шушы Нигезләмәгә 1 нче кушымта).

Инспекциянең кадрлар резервына кертүгә карата конкурс Инспекциянең дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлеге тарафыннан, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү өчен Инспекциянең белгечләргә ихтимал ихтыяҗын һәм Инспекциядә булган кадрлар резервын ел саен бәяләү нәтиҗәләре буенча оештырыла.

Инспекциянең кадрлар резервына кертүгә конкурс Инспекциянең конкурс комиссиясе тарафыннан шушы Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.4. Инспекциядә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

«җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләрендәге граждан хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен билгеле бер чорга биләү өчен билгеләнгәндә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели һәм азат итә торган «җитәкчеләр» категориясе граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә;

билгеле бер чорга хезмәт контракты төзелгәндә;

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен граждан хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгәндә;

граждан хезмәте өчен саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданинны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгән очракта.

1.5. Инспекциядә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, Инспекция боерыгы белән раслана торган вазыйфалар исемлеге буенча аерым граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә;

җитәкче карары буенча, граждан хезмәтенең кече вазыйфалар төркеменә карый торган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.6. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

сәләтләре һәм һөнәри әзерлеге нигезендә граждан хезмәтенә тигез дәрәҗәдә үтеп керүдә Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел хокукларын, шулай ук граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукларын тәэмин итү;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен аеруча туры килә торган кандидатларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатлар арасыннан сайлап алу;

граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Инспекциянең кадрлар резервын формалаштыру.

1.7. Конкурслар үткәргәндә хәл ителә торган бурычлар:

барлык кандидатлар өчен дә алар тарафыннан конкурс биремнәре һәм процедуралары үтәлгәндә тигез шартларны тәэмин итү;

кандидатларны граждан хезмәтенең мәдәниятенә, һөнәри вәкаләтлелеккә һәм шәхси-эшлекле сыйфатларга туры килү критерийлары нигезендә бәяләү;

Инспекциядә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) таләпләренә туры килә торган затларны конкурста катнашучылар арасыннан аларның конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләрен чагыштыру юлы белән ачыклау.

## II. Конкурс комиссиясе төзү һәм аның эшләү тәртибе

2.1. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы нигезендә Инспекциядә даими гамәлдә булган конкурс комиссиясе төзелә, аның составы Инспекция боерыгы белән раслана. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затларның шәхси составы үзгәртелгәндә, Инспекциянең боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2. Конкурс комиссиясе Рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итү конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясенең рәисе булмый торган чорда аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе сәркатибе конкурс комиссиясенең эшен тәэмин итә (гаризаларны терки, кабул итә, эшләрне формалаштыра, конкурста катнашучыларны исәпкә алу журналын алып бара, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерә һ. б.).

2.4. Инспекциянең конкурс комиссиясе составына җитәкченең беренче урынбасары, җитәкче урынбасарлары һәм (яки) җитәкче тарафыннан вәкаләт бирелгән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте бүлегеннән, хокукый тәэминат бүлегеннән, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрелә торган структур бүлекчәдән), Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук Инспекция гарызнамәсе буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан бәйсез экспертлар – граждан хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр сыйфатында экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә чакыртыла торган фәнни, белем бирү һәм башка оешмаларның вәкилләре керә.

Конкурс комиссиясе составына кертү өчен Инспекция каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре кандидатуралары әлеге совет тарафыннан җитәкче

гаризасы нигезендә тәкъдим ителә.

Инспекция каршындагы Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзалар санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Граждан хезмәтенең вазыйфаи вәкаләтләрен үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган вакант вазыйфасын биләүгә карата бәйге үткәрелгәндә бәйге комиссиясенең составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге калмаслык итеп төзелә.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфаларын) биләүгә карата кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр дә анда аның әгъзалары санынан кимендә өчтән ике өлеше катнашкан очракта, тулы хокуклы булып санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик комиссиянең граждан вазыйфаларын биләүче әгъзалары составында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе:

конкурсны үткәрү шартларын регламентлый торган документларны, аны үткәрү өчен кирәкле булган методик һәм бүтән материалларны раслый;

граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва белдерүче гражданнарга конкурсны үткәрү шартлары турында мәгълүмат җиткерә һәм консультацияли;

кандидатлардан алынган гарызнамәләр буенча конкурс документларын бирә;

кандидатлар тарафыннан граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) тапшырылган документларны тикшергәннән соң, конкурс комиссиясе конкурсның икенче этабына кертелгән кандидатлар исемлеген раслый;

кандидатларның куелган таләпләргә туры килүен бәяли;

конкурска йомгак ясау, кандидатны конкурста җиңүче итеп тану турында карар кабул итә, аны Инспекциянең кадрлар резервына кертү өчен тәкъдим итә.

2.9. Бәйге уздыру нәтиҗәләре буенча бәйге комиссиясе карары ачык тавыш бирү нигезендә аның утырышта катнашкан әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавыш биргәндә конкурс комиссиясе әгъзаларының фикере «килешәм» яки «каршы» сүзләре белән белдерелә. Тавышлар тигез булган очракта, бәйге комиссиясе рәисе тавышы хәл иткеч була. Конкурс комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы, кабул ителгән карар белән риза булмаган очракта, махсус фикерен белдерергә мөмкин, ул конкурс комиссиясе утырышының беркетмәсендә теркәлә һәм конкурс комиссиясендәге әлеге әгъзаның имзасы белән беркетелә.

2.10. Конкурс комиссиясенең карары кандидатның үзе булмаганда кабул ителә һәм аны Инспекциядәге граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү (аның ризалыгы белән кадрлар резервына кертү) яисә моннан баш

тарту өчен нигез булып тора.

2.11. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсендә теркәлә, ул комиссиясенең рәисе, рәис урынбасары, сәркатибе һәм утырыштка катнашкан комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана. Шул ук вакытта конкурс комиссиясе тарафыннан граждан хезмәтенә беренче мәртәбә билгеләнгәндә гражданин өчен яки граждан хезмәткәрен Инспекциянең башка төркемдәге яки категориядәге граждан хезмәтенә күчерелгәндә сынау чорының озынлыгы буенча киңәш бирелергә мөмкин.

2.12. Конкурсны оештыруны һәм аны үткәрүне, конкурс комиссиясенең эшен тәэмин итүне турыдан-туры Инспекциянең дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре бүлеге гамәлгә ашыра.

## III. Конкурста катнашучылар

3.1. Инспекциядә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча кандидатларга карата таләпләргә җавап бирә торган һәм шушы Нигезләмәнең 3.8 пунктында каралган чорда шушы Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган гражданнар конкурста катнашуга кертелә.

3.2. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата квалификация таләпләренә җавап бирмәвенә бәйле рәвештә, шулай ук граждан хезмәтенә керү һәм аны үтү өчен Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарында билгеләнгән чикләмәләре булу сәбәпле гражданин (граждан хезмәткәре) конкурста катнашуга кертелми.

3.3. Кандидатларга карата Инспекциядә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча таләпләр (шушы Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы) дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китереп билгеләнде.

3.4. Конкурста катнашу теләген белдергән Россия Федерациясе гражданы Инспекциягә түбәндәгеләрне тапшыра:

а) шәхси гариза (шушы Нигезләмәгә карата 2 кушымта);

б) Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган рәвештәге, тутырылган һәм имзаланган анкета, фотосы белән;

в) паспорт яки аны алмаштыра торган документ (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә) күчермәсе;

г) кирәкле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең (хезмәт итүгә (эшкә) бәйле эшчәнлек беренче мәртәбә гамәлгә ашырыла торган очраклардан кала) нотариаль яктан яки хезмәт итү (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе яки гражданинның эшен (хезмәт эшчәнлеген) раслый торган бүтән документлар;

белем алу турында һәм квалификация турында документларның

күчермәләре, шулай ук, ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки бирелүне раслый торган документларның, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турында документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан танылкланган күчермәләре;

д) гражданинның граждан хезмәтенә керүенә яки аны үтүенә комачаулый торган чирләре юклыгы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге 984н номерлы боерыгы белән расланган 001-ГС/у исәп рәвеше);

е) «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законда, бүтән федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.

3.5. Конкурста катнашу теләген белдергән Инспекциянең граждан хезмәткәре гаризаны җитәкче исеменә тапшыра.

3.6. Башка дәүләт органында вазыйфа биләүче, конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре Инспекциягә җитәкче исеменә шәхси гариза һәм үзе тарафыннан тутырылган, имзаланган һәм үзе граждан хезмәтен били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан танылкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган рәвештәге анкетаны фотосын теркәп тапшыра.

3.7. Гражданинның (граждан хезмәткәренең) ризалыгы белән аңа дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасы рәсмиләштерелә, әгәр дә гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан биләү өчен дәгъва белдерелгән граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса.

Гражданин тарафыннан Инспекциягә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерелә.

Граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген тикшерү бары тик ул Инспекциядәге граждан хезмәтенең иң югары вазыйфалар төркеменә карый торган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашкан очракта гына гамәлгә ашырыла.

3.8. Шушы Нигезләмәнең 3.4-3.6 пунктларында күрсәтелгән документлар аларны кабул итү турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында игълан урнаштырылган көннән башлап 21 календарь көне эчендә Инспекциягә гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша җибәрү юлы белән яисә электрон рәвештә, күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып тапшырыла.

Документларны электрон рәвештә тапшыру тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

3.9. Документларны игътибарга лаек сәбәпсез вакытында тапшырмау,

аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан (граждан хезмәткәреннән) аларны кабул итеп алудан баш тарту өчен нигез булып тора.

Хөрмәткә лаек сәбәп аркасында документларны үз вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда җитәкче аларны карап тикшерү вакытын күчерергә хокуклы.

## IV. Конкурсны уздыру методикасы

4.1. Конкурсны үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына таянган, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерияләре Инспекциядә граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләнелгән квалификация таләпләре нигезендә эшләнде.

Конкурс үткәрелә торган вазыйфалар төркеменә һәм категориясенә карап, конкурста катнашучыларны бәяләү критерияләре һәм сайланган бәяләү методлары үзгәртелергә мөмкин.

Конкурста катнашучыларны бәяләү критерияләренең якынча исемлеге һәм кыска эчтәлеге шушы Нигезләмәгә карата 4 кушымтада китерелгән.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу алар тарафыннан конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4. Бәйге ике этапта үткәрелә.

4.4.1. Беренче этапта Инспекциянең дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:

конкурс уздыру турында мәгълүмат әзерли һәм Инспекциянең рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыра, әлеге мәгълүмат түбәндәгеләрне үз эченә ала: граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасының (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасының) аталышы, әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга карата билгеләнелгән таләпләр, граждан хезмәтен үтү шартлары, документларны кабул итү урыны һәм вакыты, аталган документларны кабул итү буенча гамәлдә булган чор, конкурсны үткәрү буенча күздә тотылган дата, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, башка мәгълүмати материаллар. Конкурста катнашу өчен документларны кабул итү турындагы игълан һәм конкурс турындагы мәгълүмат шулай ук вакытлы басма матбугатта бастырылырга мөмкин;

гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан тапшырылган документларны тикшерә;

гражданинның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүен тикшерә (һөнәри белем дәрәҗәсе, граждан хезмәте (башка граждан

хезмәтенең) чоры яки белгечлеге буенча эшләү чоры (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре).

Конкурсның беренче этабы документларны кабул итү турында игълан урнаштырылган көннән башлана һәм 21 көннән ким булмаган чорда тәмамлана.

4.4.2. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив-хокукый актлары нигезендә гражданның граждан хезмәтенә керүенә каршы килә торган шартлар ачыкланган очракта, аңа җитәкче тарафыннан конкурста катнаштырудан баш тартуның сәбәпләре хакында язмача рәвештә хәбәр ителә.

4.4.3. Инспекциядә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва белдергән, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән зат әлеге карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

4.4.4. Инспекциядә граждан хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирүче кимендә ике кандидатның булуы конкурсның беренче этабын төгәлләү шарты булып тора, бу хәл кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаса яки вазыйфага квалификация таләпләренә туры килә торган бер генә кандидат булса, конкурс узмаган дип таныла. Бу очракта бердәнбер кандидатка конкурс комиссиясенең карары буенча конкурс комиссиясенең таләп ителгән кандидатлар саны булмауга бәйле рәвештә узмаган дип танылуы хакында язмача хәбәр ителә.

4.4.5. Күпчелек дәрәҗәдә билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста алга таба катнашуга тәкъдим ителгән кандидатлар исемлеген төзү турында конкурс комиссиясе карары конкурсның беренче этап нәтиҗәсе булып санала, әлеге карар конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан раслана.

4.4.6. Конкурсның беренче этабы узгач, җитәкче тарафыннан конкурсның икенче этабын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында карар кабул ителгәч, конкурс комиссиясе конкурсның икенче этабын үткәрә.

Конкурсның икенче этабын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында карар граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва белдерүчеләр тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелгәннән соң, шулай ук, зарурлык булу очрагында, дәүләт серен һәм закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгәннән соң, җитәкче тарафыннан кабул ителә. Конкурсның икенче этабы конкурста катнашу өчен документларны кабул итү тәмамланган көннән соңгы 30 календарь көннән дә соңга калмыйча уздырыла, ә дәүләт серен һәм закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта, конкурсның икенче этабын уздыру вакыты җитәкче тарафыннан билгеләнә.

Тикшерү барышында гражданинның Федераль законнар һәм Россия

Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары нигезендә граждан хезмәтенә керүенә комачау итүче шартлар ачыкланган очракта аңа конкурста катнаштырудан кире кагуның сәбәпләре турында җитәкче тарафыннан язмача рәвештә хәбәр ителә. Әгәр гражданин конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган булса, конкурста катнаштырудан кире кагу сәбәпләре хакында хәбәрләмә аңа дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

Инспекция, конкурсның икенче этабы башланырга 15 календарь көн калган чордан соңга калмыйча, үзенең рәсми сайтында һәм «Интернет» челтәренең дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы рәсми сайтында аны уздыруның датасы, урыны һәм вакыты турында, конкурста катнашуга кертелгән гражданнарның (граждан хезмәткәрләренең) (алга таба – кандидатлар) исемлеген урнаштыра һәм кандидатларга тиешле хәбәрләрне язмача рәвештә җибәрә, бу вакытта конкурста катнашу буенча документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга, – күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.

4.4.7. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

а) конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатлары бәяләнә;

б) җитәкче тарафыннан Инспекциядә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертүгә) конкурста җиңүчене билгеләү турында карар кабул ителә.

4.4.8. Конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе кандидатларны алар тарафыннан тапшырылган белем алу, граждан яки башка төрле дәүләт граждан хезмәтен үтәү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турындагы документлар нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларыннан файдаланып, конкурс процедуралары нигезендә, шул исәптән Инспекциядә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасы) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле булган мәсьәләләрдә тест һәм шәхси әңгәмә үткәрү юлы белән бәяли.

4.4.9. Инспекциядә граждан хезмәтенең билгеле бер вакант вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) кандидатларга тест үткәрү Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының 2016 елның 11 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарга тест үткәрү методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4.10. Тест үткән кандидатлар белән шәхси әңгәмәләр бәйге комиссиясе әгъзалары тарафыннан үткәрелә.

Шәхси әңгәмә кандидатларның булачак һөнәри хезмәт итү эшчәнлеге

темасы буенча конкурс комиссиясе әгъзаларының сорауларына бирелә торган җавапларыннан гыйбарәт, әңгәмә барышында конкурс комиссиясе кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын граждан хезмәте вазыйфасына һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның бүтән нигезләмәләренә карата тиешле квалификация таләпләреннән чыгып, шулай ук әлеге Нигезләмәгә һәм дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка нигезләмәләргә таянып бәяли.

4.5. Бәйге комиссиясенең бәйге комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән карары бәйгенең икенче этап нәтиҗәсе һәм бер үк вакытта бәйгенең йомгаклау нәтиҗәсе булып тора.

4.6. Конкурс комиссиясе әгъзаларыннан кандидатларга бирелгән тавышлар саны, кандидатлар биләргә теләгән вазыйфа караучы структур бүлекчә җитәкчесенең (Инспекция җитәкчелегенең) фикере Инспекциядә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидат турында карар кабул итү һәм конкурска йомгак ясау өчен нигез булып торалар.

«Хуплыйм» тавышларын иң күп җыйган кандидат конкурста җиңүче булып танылa.

4.7. Конкурс уздыру нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланган очракта, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынауларын үткәрү турында карар кабул итәргә яки яңа конкурс уздыру турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.8. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурста җиңүчене граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү турында Инспекция боерыгы чыгарыла, һәм аның белән хезмәт контракты төзелә. Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим холкына ия булган, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына карата конкурста җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәягә лаек булган кандидатны Инспекциянең кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы.

Кандидат ризалыгы белән, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы караган шул ук төркемдәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен аны кадрлар резервына кертү турында Инспекция боерыгы чыгарыла.

Граждан хезмәткәрен (гражданны) – конкурста җиңүчене кадрлар резервына кертү Инспекция боерыгы белән, Инспекция боерыгының күчермәсен граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәп рәсмиләштерелә.

4.9. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

4.10. Конкурс нәтиҗәләре хакында хәбәрләр ул тәмамланганнан соң 7 көнлек чорда кандидатларга язмача рәвештә, бу вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә. Шушы ук чорда конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат

Инспекциянең рәсми сайтында һәм «Интернет» челтәренең күрсәтелгән мәгълүмат системасында да урнаштырыла.

4.11. Инспекциядә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва белдергән, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында аларның язмача гаризалары нигезендә кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Инспекция архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң бетерелергә тиеш.

4.12. Бәйгедә катнашу (бәйгене үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынны яшәү өчен алып тору, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б.) белән бәйле чыгымнар катнашучылар тарафыннан үз акчалары исәбеннән түләнә.

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтүчелеге инспекциясе җитәкчесенә
инициаллар, фамилия)

Хезмәт язуы

Сездән Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча конкурс игълан итүегезне сорыйм
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
(вазыйфа атамасы)
____________________________________________________________________
(бүлек аталышы)

Күрсәтелгән вакантлы вазыйфаны биләүгә (күрсәтелгән вазыйфа буенча кадрлар резервына кертүгә) дәгъва кылучыга карата түбәндәге таләпләр белдерелә:
белем буенча - _______________________________________________________
дәүләт хезмәтендәге стажы һәм эш тәҗрибәсе буенча-_____________________
____________________________________________________________________
күнекмәләре һәм белемнәре буенча-___________________________________
____________________________________________________________________

Структур бүлекчә җитәкчесе
____________________________________________________________________
(имза, тулы имза)

____________________
(дата)

Килештерелде:
Җитәкче урынбасары _____________________________________________
(имза, тулы имза)

____________________
(дата)

Татарстан Республикасы
дәүләт граждан хезмәтенең
вакантлы вазыйфасын
биләүгә (кадрлар резервына
кертүгә) конкурс үткәрү
турында нигезләмәгә 2 нче
кушымта

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелеш
күзәтчелеге инспекциясе
җитәкчесенә
________________________
(инициаллар, фамилия)
кемнән ________________
(фамилия, исем, ата исеме)
белеме _____________,
(төре, уку йорты,
тәмамлау елы)
яши торган адресы: ___________
________________________,
тел. _________________________,
(эш, өй, мобиль)
e-mail ________________________

Гариза

Сездән мине Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча конкурска кертүегез турында

______________________________________________________________________
(вазыйфа атамасы)
______________________________________________________________________
(структур бүлекчә атамасы)

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә белән, шул исәптән вакантлы вазыйфаны биләү буенча билгеләнгән квалификация таләпләре белән дә, таныштым. Персональ белешмәләрнең 2006 елның 27

июлендәге «Персональ белешмәләр турында» 152-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә туры китереп эшкәртелүенә риза.

Бәйгене уздыру датасы һәм урыны турында e-mail яки күрсәтелгән кесә телефоны номерына СМС-хәбәр җибәрү ярдәмендә хәбәр алуга риза.

Гаризага кушымта итеп бирәм: ________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

(дата) (имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы
дәүләт граждан хезмәтенең
вакантлы вазыйфасын
биләүгә (кадрлар резервына
кертүгә) конкурс үткәрү
турында нигезләмәгә 3 нче
кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕНДӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕНЕҢ ВАКАНТЛЫ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮГӘ (КАДРЛАР РЕЗЕРВЫНА КЕРТҮГӘ) КАНДИДАТЛАРГА КАРАТА ТАЛӘПЛӘР**

1. Гомуми таләпләр

1.1. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән, Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (Татарстан Республикасы граждан хезмәтенең кадрлар резервы вазыйфаларын) биләү өчен кирәкле таләпләргә җавап бирә торган, 18 яшенә җиткән, Россия Федерациясенең дәүләт телен белә торган Россия Федерациясе гражданнары Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (алга таба – граждан хезмәте) биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста катнашу хокукына ия.

Граждан хезмәткәре Инспекциядәге вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста, ул үткәрелгән чорда нинди вазыйфаны биләвенә бәйсез рәвештә, гомуми нигезләрдә катнашырга хокуклы.

1.2. Татарстан Республикасы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына карата квалификация таләпләренә җавап бирмәвенә бәйле рәвештә, шулай ук граждан хезмәтенә керү һәм аны үтү өчен дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләмәләре булу сәбәпле, гражданин граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста катнашуга кертелми.

2. Квалификация таләпләре

2.1. Граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә, граждан хезмәте стажына, белгечлек, әзерлек юнәлеше, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәк булган белемнәргә һәм күнекмәләргә, шулай ук җитәкченең тиешле карары булган очракта - белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә квалификация таләпләренә туры килү таләп ителә.

2.2. Граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре

граждан хезмәте вазыйфаларының категорияләре һәм төркемнәре, граждан хезмәткәренең һөнәри хезмәт өлкәсе һәм эшчәнлеге төре нигезендә билгеләнә.

2.3. Һөнәри белем дәрәҗәсенә квалификация таләпләре:

граждан хезмәтенең иң югары һәм төп вазыйфалар төркемнәрендә «җитәкчеләр», «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)», «белгечләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен белгеч, магистратура дәрәҗәсеннән түбән булмаган югары белемгә ия булу мәҗбүри;

граждан хезмәтенең иң югары вазыйфалар төркемендә «җитәкчеләр», «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләрендәге, граждан хезмәтенең әйдәүче һәм өлкән төркемнәренең «белгечләр» категориясендәге, шулай ук граждан хезмәтенең төп һәм әйдәүче төркемнәренең «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен югары белемгә ия булу мәҗбүри;

граждан хезмәтенең өлкән һәм кече төркемнәрендә «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белемгә ия булу мәҗбүри.

2.4. Граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен кирәк булган белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча граждан хезмәте стажына яисә эш стажына карата квалификация таләпләре:

«җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләрендәге граждан хезмәте вазыйфаларының югары төркеме вазыйфаларын биләү өчен – граждан хезмәте стажы кимендә өч ел яисә белгечлек, юнәлеш буенча эш стажы җиде елдан да ким булмаган күләмдә;

граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен «белгечләр» категориясе буенча дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының югары төркеме вазыйфаларын биләү өчен - граждан хезмәте стажы кимендә өч ел яисә белгечлек, юнәлеш буенча эш стажы кимендә биш ел;

дәүләт хезмәте вазыйфаларының төп төркемендәге барлык категорияләрдәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – ике елдан да ким булмаган граждан хезмәте стажы яисә белгечлек, юнәлеш буенча өч елдан да ким булмаган эш стажы;

граждан хезмәте вазыйфаларының барлык категорияләрен дә биләгән вазыйфаларны биләү өчен – граждан хезмәте стажы кимендә бер ел яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча ике елдан да ким булмаган эш стажы.

Граждан хезмәтенең өлкән һәм кече вазыйфалар төркемнәрендә граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен граждан хезмәте стажына яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре билгеләнми.

Граждан хезмәте стажын билгеләгәндә шулай ук тиешле вазыйфаи төркемнәр вазыйфаларында, федераль дәүләт хезмәтенең башка төр вазыйфаларында һәм хәрби вазыйфаларда, дәүләт вазыйфаларында, муниципаль вазыйфаларда, тиешле вазыйфаи төркемнәр вазыйфаларында, федераль законнар нигезендә бүтән вазыйфаларда эш стажы шулай ук исәпкә алына.

2.5. Граждан хезмәте стажына яисә белгечлеккә, әзерлек юнәлеше буенча

эш стажына карата әлеге Таләпләрнең 2.4 пунктында билгеләнгән квалификация таләпләре, граждан хезмәтенең төп һәм әйдәп баручы вазыйфалары төркемнәрендә «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендәге һәм граждан хезмәтенең төп һәм әйдәп баручы төркемнәрендәге вазыйфаларның «белгечләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә эшчәнлек юнәлеше буенча туры килә торган фәнни дәрәҗәсе булган затлар өчен дәүләт органы җитәкчесенең карары белән исәпкә алынмаска мөмкин.

2.6. Иң яхшы билгеләр белән белгеч яисә магистр дипломнары булган затлар өчен диплом бирелгән көннән өч ел дәвамында граждан хезмәте стажына яки белгечлек, граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфаларын биләү өчен әзерлек юнәлеше буенча эшләүгә карата квалификация таләпләре билгеләнә – граждан хезмәте яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер еллык эш стажы.

2.7. Вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә квалификация таләпләре граждан хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә бәйле рәвештә аның вазыйфаи регламенты белән билгеләнә. Граждан хезмәткәренең вазыйфаи регламентында шулай ук граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен кирәк булган белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча квалификация таләпләре каралырга мөмкин.

Татарстан Республикасы
дәүләт граждан хезмәтенең
вакантлы вазыйфасын
биләүгә (кадрлар резервына
кертүгә) конкурс үткәрү
турында нигезләмәгә 4 нче
кушымта

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕНДӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕНЕҢ ВАКАНТЛЫ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮГӘ (КАДРЛАР РЕЗЕРВЫНА КЕРТҮГӘ) КОНКУРСТА КАТНАШУЧЫЛАРНЫ БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЯЛӘРЕ

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте мәдәниятенә туры килүе

1.1. Һөнәри максатчанлыгы

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә һөнәрдә шәхси потенциал үстерүгә омтылуы, дәүләт идарәсе өлкәсендә хезмәттә үсүне күздә тотуы.

1.2. Гражданлык позициясе

Эшчәнлектә җәмгыятькә һәм дәүләткә хезмәт итүе, законнарны, хезмәт этикасы кагыйдәләрен саклау принципларын үтәве.

1.3. Һөнәри позициядәге активлыгы

Куелган мәсьәләләрне хәл иткәндә инициатива күрсәтергә омтылуы; мөмкин булган иң яхшы нәтиҗәгә ирешү өчен хәлдән килгәнчә тырышлык күрсәтергә әзер булуы, физик һәм эмоциональ басым шартларында нәтиҗәле эш-гамәл кылуга (стрессларга каршы торуга) сәләтле булуы.

1.4. Үз-үзен үстерүгә әзер булуы

Үз белемнәрен, осталыкларын һәм күнекмәләрен даими камилләштерергә, карашларын киңәйтергә, катнаш һөнәр өлкәләрендә белемнәр һәм тәҗрибә алырга омтылуы.

2. Граждан хезмәткәренең һөнәри вәкаләтлелеге

2.1. Белем дәрәҗәсе

Төп һәм өстәмә һөнәри белем дәрәҗәсе, юнәлеше һәм сыйфаты.

2.2. Һөнәри тәҗрибәсе

Тиешле һөнәр өлкәсендәге эшчәнлек итү озынлыгы һәм үзенчәлекләре;

һөнәри эшчәнлегендә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешүе; карьерасының үзенчәлекләре.

2.3. Махсус һөнәри белемнәре, осталыклары һәм күнекмәләре

Тиешле өлкәдә вазыйфа бурычларын нәтиҗәле башкару мөмкинлеген бирә торган һөнәри белемнәре дәрәҗәсе;

һөнәри эшчәнлекне регламентлаучы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын белүе;

заманча профессиональ технологияләр белән эш итә белүе.

2.4. Гомуми инструменталь күнекмәләре

Һөнәри эшчәнлекнең гомуми нәтиҗәлелеген арттыра торган күнекмәләргә ия булу дәрәҗәсе (компьютер белүе, гомуми грамоталылыгы, чит телләр белүе һ. б.).

3. Граждан хезмәткәренең шәхси-эшлекле сыйфатлары

3.1. Аналитикага бәйле сәләтләре

Мәгълүматларны анализлау һәм структуралаштыруны таләп итә торган катлаулы мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлеген бирә торган системалы һәм сыгылмалы фикерләү дәрәҗәсе;

яңа, стандарт булмаган чишелешләр таба белү сәләте.

3.2. Нәтиҗәле коммуникацияләү күнекмәләре. Эшлекле сөйләм этикасын саклавы;

үз фикерен дәлилләп яклау һәм оппонентларны ышандыру сәләте;

эшлекле сөйләшүләр алып бару күнекмәләренә ия булуы.

3.3. Җаваплылыгы

Карарларны кабул итүдә нигезле һәм мөстәкыйль эш итүе;

нәтиҗәгә ирешүдә үз өстенә алган йөкләмәләрне үтәргә әзер булуы.

3.4. Оештыруга бәйле сәләтләре

Үз эшчәнлеген һәм үзенә буйсынып эшләүчеләр эшчәнлеген нәтиҗәле планлаштыру, вазыйфаларны, вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны бүлеп бирү хисабына нәтиҗәләргә ирешә белүе.

---